# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Балалар санаториясе торак пунктында территориясендә 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 15 ноябре №3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Балалар санаториясе торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Балалар санаториясе торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәге гражданнар категорияләреннән тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә:

а) 1 төркем инвалидлар

в) СВО катнашучысы һәм аларның гаилә әгъзалары

Аерым категория гражданнар өчен:

а) күпбалалы гаиләләр,

б) уку йортлары студентлары

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Балалар шифаханәсе бистәсендә урамнарны яктырту җайланмасын урнаштыру

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов